**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Каенсар торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел.

№ 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Каенсар торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Каенсар торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1.Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (Каенсар авылы зираты территориясен чистарту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2.Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Каенсар авылы су башнясына будка төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).”

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Каенсар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.